ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.03.2017 8

с. Нижний Услон

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең торак пунктларын санитар-экологик чистарту икеайлыгы үткәрү турында

Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегенең торак пунктларын төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм аларның торышын халыкның экологик иминлегенә туры килә торган итеп китерү;

Карар бирәм:

1. 2017 елның 1 апреленнән 31 майга кадәр Түбән Ослан авыл җирлегенең торак пунктлары (алга таба - ике айлык) территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык игълан итәргә.

2. Түбән Ослан авыл җирлегенең төзекләндерү комитеты составын 2017 елның 01 апреленнән 31 маена кадәр расларга ( 1 нче кушымта)

3. Төзекләндерү чаралар планын 2017 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр ( 2 нче кушымта) расларга.

4. Түбән Ослан авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма, учреждениеләр җитәкчеләренә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, якындагы территорияләрне санитар чистарту эшен оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Урыннарда агач һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын ремонтлау эшләрен оештырырга.

6. Авыл җирлеге территориясендә күчемсез милеккә ия булган гражданнарга кемнеке булуга карамастан, үзләренең йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш уздырырга тәкъдим итәргә.

7. Хәзерге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә. Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының

Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.З.Шәйдуллин

Югары Ослан  муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге
Башкарма комитетының
15.03.2017 ел № 8 карарына
1нче кушымта

Түбән Ослан авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составы

1. Шәйдуллин Айдар Зәки улы - Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы

2. Түбән Ослан авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Лилия Васильевна Чемоданова

3. Шәрәфетдинов Рамил Таһир улы - 1 нче Түбән Ослан сайлау округы депутаты

4. Галиев Эльс Солтан улы - 5 Түбән Ослан сайлау округы депутаты

Югары Ослан муниципаль районының
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.З.Шәйдуллин

Югары Ослан  муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге
Башкарма комитетының
15.03.2017 ел № 8 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен санитар чистарту буенча чаралар планы

№  Чара исеме  Дата  Җаваплылар

1. Гражданнар җыелышларын, авыл җирлеге Советының төзекләндерү мәсьәләсе буенча утырышын уздырырга, 01.04.2017,   авыл җирлеге башлыгы, җирлек халкы

2. Каты көнкүреш калдыкларына дача хуҗалыклары белән шартнамәләр төзергә. Юл буе полосаларын җыю буенча бердәм санитар көн билгеләргә - чәршәмбе
01.05.2017
01.04. -31.05.2017ел, А Цветков. Авыл җирлеге башлыгы, оешма җитәкчеләре

3. Сәүдә нокталары янындагы территорияләрдә санитар нормаларның үтәлешен оештыруны һәм системалы рәвештә тикшерүне оештырырга, даими рәвештә, авыл җирлеге башлыгы,

4. Торак пунктлар эчендә юл буе полосаларын һәм баганаларны җыештыру, 20.04. - 25.04.2017 ел, Авыл җирлеге башлыгы, оешма җитәкчеләре

5. Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждениеләрнең, оешмаларның фасадларын ремонтлау,01.05 - 31.05.2017 ел,учреждение, оешма җитәкчеләре

6. Түбән Ослан авылында һәйкәлләрне төзекләндерү.Чәчәкләр утырту. 2017елның 1 маена кадәр.Башкарма комитет һәм мәдәният хезмәткәрләре

7. Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү. 01.05 - 31.05.2017 ел. Авыл җирлеге башлыгы, оешма җитәкчеләре, халык.

8. Авыл җирлегенең торак пунктларында яшел үсентеләр утырту. Чәчәкләр утырту.
01.05 - 31.05.2017 ел. Авыл җирлеге башлыгы, оешма җитәкчеләре, халык.

9. Су җыю башняларын төзекләндерү. 01.04.- 31.05.2017 ел. Авыл җирлеге башлыгы

10. Җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (грейдерлау, чокыр ремонты).
15.04. - 31.05.2017 ел. Авыл җирлеге башлыгы, предприятие җитәкчеләре

Югары Ослан муниципаль районының
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы                                        А.З.Шәйдуллин